СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.05.2026 № 10/1

На №_________от_____________

**КАРАР**

**Тукай муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чаралары турында**

«Тукай муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чаралары турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Район Башкарма комитетына:

- төрле мәдәният вәкилләре арасында элемтәләрне ныгыту өчен, «2025-2030 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасы чараларының үтәлешен тәэмин итәргә;
- Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге белән берлектә, чит ил гражданнарының авыл җирлекләренә килүе һәм аннан китүе турында мәгълүмат алмашу буенча үзара хезмәттәшлекне җайга салырга.

3. Авыл җирлекләре Башлыкларына тәкъдим итәргә:

- РФ Эчке эшләр министрлыгының Тукай муниципаль районы буенча бүлеге белән берлектә, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның законсыз яшәү һәм законсыз хезмәт эшчәнлеген кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча эшне дәвам итәргә;
- дини объектларга хокук билгели торган документларны рәсмиләштерү эшен тәмамларга.

4. Дини оешмалар җитәкчеләренә район халкы өчен мәгърифәтчелек һәм белем бирү чаралары үткәрергә тәкъдим итәргә.
5. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә район халкын рухи-әхлакый тәрбияләүгә юнәлтелгән материалларны бастырып чыгаруны дәвам итәргә һәм милләтара һәм конфессияара мәсьәләләрне даими яктыртырга.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм

Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе К.Р. Нәҗмиев